РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ
ПОДГОРНО-БАЙЛАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423711, Республика Татарстан
Мензелинский район, с.Подгорный
Байлар, ул.Центральная, д.14 а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАУАСТЫ БАЙЛАР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423711, Татарстан Республикасы,
Минзәлә районы, Тауасты Байлар
авылы, Уззэк урамы, 14 а

# КАРАР

## Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлеге составына кергән Дәвек торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2019 ел, 17 ноябрь** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ нең 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы №45-ЗРТ Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 17 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар түбәндәге мәсьәлә буенча җыен беркетмәсе төзелде: “2020 елда Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Дәвек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1-2 төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?”

-су этем башнясын лицензияләү (койма материал сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эшләү, су анализы, проектлау) буенча түләү.

-кышкы чорда грейдерлау,

-скважина очен насос сатып алу

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 241 гражданнар җыенында катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар җыенында катнашучылар саны 97 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:
“Әйе” позициясе өчен 97 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде;

“Юк” позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Дэвек торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – гамәлдә дип танырга.

2.“2020 елда Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Мияш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1-2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?” мәсьәләсе буенча карарны танырга:

-су этем башнясын лицензияләү (койма материал сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эшләү, су анализы, проектлау) буенча түләү.

-кышкы чорда грейдерлау,

-скважина очен насос сатып алу

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Тауасты Байлар авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, Минзәлә муниципаль районы сайтында: http://menzelinsk.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы һәм http://pravo.tatarstan Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматенең рәсми порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Гамәлдәге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенә җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Тауасты Байлар авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе: Гәрәева З.С.